РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 4 нче сентябре** **г. Чистополь** **№ 46/1**

Чистай муниципаль районы Советының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының социаль - икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында»гы 2016 елның 10 августындагы 12/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында»гы 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, 2015 елның 16 мартындагы 12-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында»гы Татарстан Республикасы Законы һәм 2015 елның 15 нче мартындагы “Татарстан Республикасынды 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында”гы 40-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Чистай муниципаль районы Советы

**Карар бирә:**

1. Чистай муниципаль районы Советының «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының социаль - икътисадый үсеше стратегиясен раслау турында»гы 2016 елның 10 августындагы 12/1 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Чистай муниципаль районы социаль-икътисадый үсеше Стратегиясенә үзгәрешләр кертергә, аны әлеге карарның кушымтасы нигезендә бәян итәргә.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны сәнәгать, эшмәкәрлек һәм кече бизнесны үстерү мәсьәләләре буенча Чистай муниципаль районы Советының даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль район башлыгы Д.А. Иванов